**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы №82 «14» декабрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2013 елның 07 феврадендәге 64 номерлы Үчәлле авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү шартлары һәм тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (15.07.2016 №36, 31.08.2017.№64, 13.10. 2017 №71, 24.11.2017 №79 карарлар редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Советы карарын «Депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2007 елның 17 декабрендәге 722 номерлы карарына туры китерү максатларында

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2013 елның 07 феврадендәге 64 номерлы Үчәлле авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү шартлары һәм тәртибе турындагы Нигезләмәгә (15.07.2016 №36, 31.08.2017.№64, 13.10. 2017 №71, 24.11.2017 №79 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктта:

а) унынчы абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Ай саен акчалата бүләкләү, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, шулай ук Татарстан Республикасының норматив актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла. »;

б) түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы норматив актлары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Өчиле авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә җирлек башлыгына эш нәтиҗәләре буенча премияләр һәм башка түләүләр түләнә. "

1.2.8 пунктта «муниципаль хезмәткәр» сүзләреннән соң «, Главаның айлык акчалата бүләкләнүенә,» сүзләрен өстәргә.

1.3. 2.8нче пункт таблицасында «Муниципаль хезмәт стажы» сүзләрен «Муниципаль хезмәтнең гомуми стажы, муниципаль вазыйфаны биләүнең гомуми стажы» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 4 бүлекнең аталышын «Җирлек башлыклары» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 4 бүлемтәгә түбәндәге эчтәлекле 4.2 пункт өстәргә:

«4.2. Җирлек башлыгының хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда айлык акчалата түләүләрне түләү өчен җибәрелә торган акчаларның суммасыннан тыш, түләү өчен акчалар каралган (бер елга исәпләгәндә):

1) айлык акчалата бүләкләү - айлык унбер акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә;

2) тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү - айлык акчалата түләүдән артмаган күләмдә;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү ай саен бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләүдән артмаган күләмдә. "

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина